**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы  Чуаш Киштәге авыл җирлегенең  Чуаш Киштәге авылында гражданнар җыены карары**

14 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлегенең Чуаш Киштәге авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Чуаш Киштәге авыл җирлегенең  Чуаш Киштәге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия  балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә

- Чуаш Киштәге авылында юлларны ремонтлауга, зиратны төзекләндерүгә, юлларны карап тотуга (хезмәтләр һәм килешү буенча эшләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Чуаш Киштәге авыл җирлегенең  Чуаш Киштәге авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чуаш Киштәге авыл җирлеге башлыгы _________ И.А.Павлов

Гражданнар җыены секретаре _________ Т.Н.Зайцева